ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА НИЖНЕКАМСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

пр. Строителей, д.12, г. Нижнекамск, 423570

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

20 03 2023 г. № 54

Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының 2021 елның 4 августындагы 232а номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү турында

«Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законының 20 статьясы, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының 2021 елның 4 августындагы 232а номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына, 1.5 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«ДТФ - «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, турыдан-туры аны тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәис) тарафыннан төзелгән яки вәкаләт бирелгән республика коммерцияле булмаган оешмасы;».

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының торак сәясәте бүлеге җитәкчесе Р.Ф. Хәйруллинга йөкләргә.

ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН
ИНН 1651044881

Җитәкче К.Р. Нәҗмиев